СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.01.2023 г. Заинск № 119

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 14 ноябрендәге 185 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» ТР Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәрендә муниципаль хезмәт турында" нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 14 ноябрендәге 1855 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11 пунктны өстәргә:

«11) алар тарафыннан чит ил агенты статусы алу.»;

1.2. 24 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 5 пункт белән тулыландырырга:

«5) муниципаль хезмәткәр тарафыннан чит ил агенты статусын алу.»;

1.3. 35 статьяның 4 пунктында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башлыгы урынбасары Е.В.Недошивинага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**